Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Иске Каразирек авыл җирлеге Яңа Каразирек торак пунктында 2025 елда гражданнарга үзара салым кертү турында

**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

№ 6 14 ноябрь 2024 ел

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ санлы Федераль законның 25.1, 56 маддәләре, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе нигезендә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Иске Каразирек авыл җирлегенең Яңа Каразирек торак пунктында гражданнар җыены

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Иске Каразирек авыл җирлеге Яңа Каразирек торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, махсус хәрби операциядә катнашучылардан сугыш хәрәкәтләрендә катнашучыларның якын туганнарыннан (ата-аналары, балалары), Россия Армиясенә хәрби хезмәткә чакырылучы гражданнардан, көндезге бүлектә укучы студентлардан тыш, 2025 елда 1000 (бер мең) сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны:

- каты коммуналь калдыкларны туплау мәйданчыклары төзү, каты коммуналь калдыкларны җыю өчен контейнерлар сатып алу, рөхсәтсез чүплекләрне бетерүгә (Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Иске Каразирек авыл җирлегенең Яңа Каразирек торак пунктында контейнер мәйданчыкларын төзекләндерүгә (төзелеш материаллары сатып алу, транспорт чыгымнары, бетонлаштыру, эшләр һәм шартнамә буенча хезмәт күрсәтүләр өчен түләү));

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тотуга (Яңа Каразирек торак пунктының Комсомол урамындагы юл-урам челтәрен норматив хәлгә китерүгә (төзелеш, реконструкция, асфальтлау, ремонтлау, вак таш салу, ташу, төзелеш материаллары сатып алу, килешү буенча эшләр өчен түләү)» юлларга.

3.Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында түбәндәге веб-адрес буенча халыкка җиткерергә: http://pravo.tatarstan.ru, Ютазы муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында түбәндәге веб-адрес буенча урнаштырырга: http://jutaza.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Иске Каразирек авыл җирлеге территориясендә махсус мәгълүмат стендларында элэргә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
Иске Каразирек авыл җирлеге башлыгы И.Р.Гәрәев